| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.03.2023ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 899** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 05 октябрендәге 2626 номерлы карары белән расланган, белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 05 октябрендәге 2626 номерлы карары белән расланган, белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне таныклый торган башка документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

1.2. Административ регламентның 2 бүлегенең 2.10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан тарафыннан бирелә.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми».

1.3. Административ регламентның 3 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 3.3.3.6.-3.3.3.7 пунктлар өстәргә:

«3.3.3.6. Гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт нәтиҗәләренә карата да, муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары.

«3.3.3.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе административ регламентның 1.2.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә, гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт нәтиҗәләренә карата да, муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, билгеләнми».

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин